ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРУССИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.16в, с. Старые Уруссу, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 16в йорт, Иске Урыссу авылы,
423960

Тел.:(85593) 4-42-31, факс:4-41-52, e-mail: Uruss.Utz @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 6 2018 елның 21 мае

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү буенча Бердәм тариф челтәре таралмаган
Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге
Башкарма комитеты хезмәткәрләренең хезмәтләренә
түләү турында

2018 елның 30 мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсенең Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 195 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган эш хакы айлык вазыйфаи окладтан, тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазифаи окладка өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск биргәндә, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләүләрдән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора. Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук берничә эш башкарган өчен өстәмә түләүләр, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын башкару да кертелә;

Башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме 11 163,0 сум тәшкил иткән суммадан башлап исәпләнә;

2. Расларга:

1 нче кушымта нигезендә, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләүдә кулланыла торган коэффициентны.

3. Башкарма комитет хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне:

| Эш стажы түбәндәгечә булганда | Ай саен өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эшне катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү;

3) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән булса, бер тапкыр түләнә торган түләү билгеләнгән вакытка пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрьдә түләнә, эштән азат ителгән очракта - эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча.

Хезмәткәр эшенең беренче елында еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт, эшкә кергән көннән башлап агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

6) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм күрсәтелә.

4. Хезмәткәрләргә берничә эшне берьюлы алып барган, хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазифаларын башкарган өчен билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 процентына кадәр күләмдә билгеләргә.

5. Хезмәткәрләргә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләрне гамәлгә ашырырга.

6. Вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчалар суммасыннан тыш, Башкарма комитет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү

фондын формалаштырганда түләү өчен түбәндәге чаралар каралган (елга исәпләгәндә, 12 вазыйфаи окладтан чыгып):

1) тиешле елларны эшләгән өчен айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазифаи окладка айлык өстәмә - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр - вазыйфаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның ике проценты күләмендә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә һәм матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр бирелә торган түләү - вазыйфаи окладларның 10 проценты күләмендә.

7. Башкарма комитет хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме, шулай ук Башкарма комитет хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме арту ягына тулы сумга кадәр түгәрәкләп исәпләнергә тиеш дип билгеләргә.

8. Әлеге карар 2018 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Урыссу авыл җирлеге Башлыгы
вазифаларын башкаручы Ф.Г. Әминова

Кушымта №1
Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу авыл
җирлеге Башкарма комитеты карарына
2018 елның "21" маеннан

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ БУЕНЧА БЕРДӘМ ТАРИФ ЧЕЛТӘРЕ КАГЫЛМАГАН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРЫССУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНДӘ БЮДЖЕТ ӨЛКӘСЕНЕҢ АЕРЫМ ОЕШМАЛАРЫ СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘЛӘРНЕҢ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ҺӘМ БЕЛГЕЧЛӘРЕ ВАЗИФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘГӘНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН КОЭФФИЦИЕНТЛАР**

| Вазифаның исеме | Коэффициент |
|---|---|
| | V төркем |
| Баш белгеч | 1,10 |